Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Советы

КАРАР

2021 елның 26 марты № 8/10

Дебитор бурычын бетерү турында

Россия Федерациясе Граждан кодексының 196, 200 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән бирелгән кредитлар (заемнар) буенча бурычлар Реестры нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы оешмаларының дәгъвалау вакыты чыгу сәбәпле дебитор бурычларын бетерүне танырга һәм аларны исәптән чыгарырга.
2. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.
3. Әлеге карар Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Глава Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан, Председатель Совета Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан: М.Р. Гафаров

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль
районы Советының
2021 елның 26 мартындагы
8/10 номерлы карары белән
расланган

Бюджет кредиты бурычлары
бетерелергә тиешле оешмалар исемлеге

| Хуҗалыкларның исемнәре | Нигез | Шартнамәнең датасы һәм номеры | Сумма, сумнарда | Бюджет кредиты нинди максатларга бүлеп бирелгән | Кредит бирү датасы |
|---|---|---|---|---|---|
| Дәүләт ветеринария берләшмәсе | район администрациясе Башлыгының 2002 елның 22 маендагы боерыгы | 22.05.2002 № 8-02 | 100 000,00 | медикаментлар сатып алу | 23.05.2002 |
| «Городище» ҖЧҖ | район администрациясе Башлыгының 2004 елның 30 октябрендәге боерыгы | 29.11.2004 № 6-04 | 49 900,00 | минераль ашламалар сатып алу | 29.11.2004 |
| «Алмаз» КФХ | район администрациясе Башлыгының 2004 елның 30 октябрендәге боерыгы | 29.11.2004 № 7-04 | 50 918,93 | минераль ашламалар сатып алу | 29.11.2004 |